КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 май г.Казань № 454

Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 80 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 17 май, 454 нче
карары белән расланды

**Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү**
кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 80 статьясы нигезендә бу Кагыйдәләр дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар (алга таба шул ук эзлеклелектә – юридик затлар, карарлар) кабул итү тәртибен билгели.

1.2. Карарлар Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларындагы максатлардан һәм бурычлардан, Татарстан Республикасы Президентының йөкләмәләреннән һәм күрсәтмәләреннән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәләреннән чыгып кабул ителә.

1.3. Карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый акты формасында кабул ителә.

## II. Карар проектын әзерләү

2.1. Карарны әзерләү инициаторы булып Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы буларак Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә юридик затларга бюджет инвестицияләре бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче) тора.

2.2. Карар проектында шул исәптән түбәндәгеләр билгеләнә:

а) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче исеме;

б) юридик зат исеме;

в) бюджет инвестицияләрен бирү максаты;

г) бюджет инвестицияләрен бирү нәтиҗәсе;

д) юридик зат тарафыннан ирешелергә тәэмин ителергә тиешле башка күрсәткечләр (кирәк булганда);

е) бюджет инвестицияләре күләме;

ж) алга таба башка оешмаларның устав (җыелма) капиталларына кертемнәр, башка оешмалар мөлкәтенә аларның устав (җыелма) капиталларын арттырмый торган кертемнәр бирү өчен бюджет инвестицияләре бирелгән очракта, һәр шундый оешмага карата – еллар буенча бүлеп, әлеге кертемнәрнең исеме һәм гомуми күләме яисә бу оешмаларны сайлап алу тәртибе һәм (яки) критерийлары (әлеге оешмаларны билгеләү мондый сайлап алу нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырылса).

2.3. Юридик зат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карар проекты кертелгән айга кадәрге айның беренче көненә дә иртәрәк булмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

а) юридик затның салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмау;

б) юридик затның субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка норматив хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

в) юридик зат үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, юридик затның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

г) юридик зат чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

д) юридик затка карар проектында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирелмәү.

2.4. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче юридик заттан аның бу Кагыйдәләрнең 2.3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслый торган түбәндәге документларны алуны тәэмин итә:

а) юридик зат тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсе үтәлү турында салым органының белешмә кәгазе (әлеге белешмә кәгазе тапшырылмаган очракта, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

б) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат турында белешмәләр бирелгән өземтә (өземтәләр) (әлеге белешмә кәгазе тапшырылмаган очракта, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

в) юридик затның бу Кагыйдәләрнең 2.3 пунктындагы «б» пунктчасында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган, юридик затның җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

г) юридик затның соңгы ике ел өчен бухгалтерлык балансыннан, финанс нәтиҗәләре турындагы хисаптан торган еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күчермәсе.

2.5. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче карар проектын, аңлатма язуын, финанс-икътисад нигезләвен һәм Татарстан Республикасы милкендә юридик затның устав (җыелма) капиталында акцияләр (өлешләр) булу турында белешмәләр бирелгән мәгълүматны теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

2.6. Карарга үзгәрешләр кертү бу Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Бюджет инвестицияләре төбәк проект нәтиҗәсенә ирешү максатларында бирелгән очракта, тиешле төбәк проекты паспортына тиешле үзгәрешләр билгеләнгән тәртиптә кертелгәндә карарга үзгәрешләр кертү таләп ителми.

___________________________